КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 9 июль г.Казань № 556

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәскәү – Түбән Новгород – Казан тиз йөрешле автомобиль юлы. Мәскәү – Түбән Новгород – Казан тиз йөрешле автомобиль юлы төзелеше, 7 этап, 586 км – 663 км, Чуваш Республикасы, Татарстан Республикасы (А-151 «Цивильск – Ульяновск» федераль әһәмияттәге автомобиль юлы белән кисешкән урыннан алып Р-241 «Казан – Буа – Ульяновск» автомобиль юлы белән кисешкән урынга кадәр)» һәм «Мәскәү – Түбән Новгород – Казан тиз йөрешле автомобиль юлы. Мәскәү – Түбән Новгород – Казан тиз йөрешле автомобиль юлы төзелеше, 8 этап, 663 км – 729 км, Татарстан Республикасы (Р-241 «Казан – Буа – Ульяновск» федераль әһәмияттәге автомобиль юлы белән кисешкән урыннан алып Мишә елгасына кадәр)» объектларын төзү максатыннан Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен резервлау турында» 2020 ел, 16 октябрь, 934 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Җир кодексының $70^1$ статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен җирләрне резервлау белән бәйле кайбер мәсьәләләр турында» 2008 елның 22 июлендәге 561 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең транспорт стратегиясе турында» 2008 елның 22 ноябрендәге б-1734 номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль транспорт (тимер юл, һава, диңгез, эчке су

транспорты) һәм федераль әһәмияттәге автомобиль юллары өлкәсендә Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2013 елның 19 мартындагы б-384 номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Транспорт системасын үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 20 декабрендәге 1596 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 30 сентябрендәге б-2101 номерлы боерыгы белән расланган 2024 елга кадәрге чорга магистраль инфраструктураны модернизацияләү һәм киңәйтүнең комплекслы планы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 31 декабрендәге б-2146 номерлы боерыгы белән расланган Озак вакытлы чорга (2010 – 2024 еллар) «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясе эшчәнлеге программасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәскәү – Түбән Новгород – Казан тиз йөрешле автомобиль юлы. Мәскәү – Түбән Новгород – Казан тиз йөрешле автомобиль юлы төзелеше, 7 этап, 586 км – 663 км, Чуваш Республикасы, Татарстан Республикасы (А-151 «Цивильск – Ульяновск» федераль әһәмияттәге автомобиль юлы белән кисешкән урыннан алып Р-241 «Казан – Буа – Ульяновск» автомобиль юлы белән кисешкән урынга кадәр)» һәм «Мәскәү – Түбән Новгород – Казан тиз йөрешле автомобиль юлы. Мәскәү – Түбән Новгород – Казан тиз йөрешле автомобиль юлы төзелеше, 8 этап, 663 км – 729 км, Татарстан Республикасы (Р-241 «Казан – Буа – Ульяновск» федераль әһәмияттәге автомобиль юлы белән кисешкән урыннан алып Мишә елгасына кадәр)» объектларын төзү максатыннан Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен резервлау турында» 2020 ел, 16 октябрь, 934 нче карарына, 1 – 3 кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына билгеләнгән тәртиптә:

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләр кертү өчен документлар кертергә;

бу карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга;

бу карарны муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә рәсми бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасының Апас, Югары Ослан, Кайбыч, Лаеш һәм Питрәч муниципаль районнарына җибәрергә.

3. Бу карар резервлана торган җир кишәрлекләре урнашу урыны буенча рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыгарга тиеш һәм басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин